ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2023 г. Казань № 779-175/кс-2023

Әлмәт муниципаль районы «Светсервис» муниципаль унитар предприятиесе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2024 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2023 №60-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра торган Әлмәт муниципаль районы «Светсервис» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Светсервис» МУП) тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга Федераль тарифлар хезмәтенең 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрнең 114.1 пункты нигезендә билгеләнә торган формула рәвешендә билгеләргә:

$$Т^{гвс}_{закр} = Т_{хвс} + Т^{тэ}_{i} * Q^{т/э}$$

биредә:

$Т_{хвс}$ – «Альметьевск-Водоканал» акционерлык җәмгыяте өчен 2024 елга эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2023 № 624-90/кс-2023 карары белән билгеләнгән тариф;

$Т^{тэ}_{i}$ – җылылык энергиясенә (егәрлегенә) компонент яклар килешүе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы

карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую нигезләренең 5(5) пункты нигезендә билгеләнә торган тариф;

$Q^{т/э}$ – бер кубик метр салкын суны җылыту өчен кирәкле җылылык энергиясе күләме (саны), 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 26.10.2017 № 189/о боерыгы белән, 2024 елның 1 июленнән 2024 елның 31 декабренә кадәр Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 16.11.2023 № 168/о боерыгы белән билгеләнә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Светсервис» МУП ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев